**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Улица М.Титова, дом 7,
Черемшан село, 423100

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы,
423100

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

№ 36 28 сентябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 сентябрендәге 176 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 сентябрендәге 176 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары Л.С. Гатина